Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР**

05.11. 2021 ел. №4

Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең
Чуаш Енорускино авылында халык җыенын гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.11.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Илтерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,
КАРАР БИРӘМ:

1. ТР, Аксубай районы, Чуаш Енорускино авылы, Ленин урамы, 18а йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында 2021 елның 16 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Чуаш Енорускино авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының **беренче этабын билгеләргә**.
2. ТР, Аксубай районы, Чуаш Енорускино, Ленин урамы, 18а йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында 2021 елның 16 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Чуаш Енорускино авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының **икенче этабын билгеләргә**.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегенең Чуаш Енорускино авылында яшәүчеләр исемлеген 2 өлешкә бүләргә:

1) Көнчыгыш ур., Урман ур., Төньяк ур.;
2) Южная ур., Школьная ур., Садовая ур., Школьная тыкрыгы, Полевая ур., Пионерская ур.;.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән **сез риза буласызмы?**

**1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
- вак таш капламалы поселок эчендәге юлларын чокырлы ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- кышкы чорда юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эшләр өчен түләү).

**2) Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**3) КККны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**
- контейнерлар сатып алу, контейнер киртәләр төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**4) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:**
- Чуаш Енорускино авылында су үткәргеч челтәрләрен ремонтлау, суэтем башнясын койма белән әйләндереп алу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)).

**5) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү** (янгын сүндергечләрне, электр белән тәэмин итү челтәренә тоташтырылган яктылык күрсәткечләре сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, әлеге карарны авыл җирлеге халкы күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы С. М. Маклаков